КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 7 июль г.Казань № 796

Гражданнарның урманнарда булуын һәм аларга транспорт чаралары белән керүен чикләүне кертү турында

Россия Федерациясе Урман кодексының $53^5$ статьясы, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында гражданнарның урманнарда булуын һәм аларга транспорт чаралары белән керүен чикләү, урманнарда билгеле бер эшләр төрләрен башкару тәртибен һәм Урманнарда санитария иминлеген тәэмин итү максатларында гражданнарның урманнарда булуын һәм аларга транспорт чаралары белән керүен чикләү, урманнарда билгеле бер эшләр төрләрен башкару тәртибен раслау турында» 2016 елның 6 сентябрендәге 457 нче боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә урманнарда янгын чыгу куркынычының IV классы билгеләнүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Әгерҗе, Азнакай, Аксубай, Әлки, Әлмәт, Арча, Баулы, Биләр, Болгар, Бөгелмә, Буа, Алабуга, Зәй, Зеленодольск, Ислейтар, Кайбыч, Кәләй, Кама, Кызыл Йолдыз, Лаеш, Лениногорск, Лубян, Мамадыш, Минзәлә, Түбән Кама, Нурлат, Идел буе, Шәһәр яны, Саба, Тәтеш һәм Чирмешән урманчылыклары чикләрендә урман фондының бөтен территориясендә, урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, гражданнарның урманнарда булуын, аларга транспорт чаралары керүен бу карар үз көченә кергән көннән 21 календарь көнгә чикләү кертергә.

2. Бу карарның 1 пункты нигезләмәләре түбәндәгеләргә кагылмый дип билгеләргә:

дәүләт хакимияте органнарының вазыйфаи затларына һәм хезмәткәрләренә, махсуслаштырылган учреждениеләрнең, җирле үзидарә органнарының, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы һәм министрлыкның ведомство буйсынуындагы учреждениеләренең, Татарстан Республикасы Гражданнар

оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенең урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чараларын гамәлгә ашыруга җәлеп ителгән хезмәткәрләренә, шулай ук учреждениеләрнең, оешмаларның «2023 елда янгыннар чыгу куркынычы булган чорда Татарстан Республикасы территориясендә урман янгыннарын сүндерүнең җыелма планын раслау турында» Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 7 мартындагы 105 номерлы боерыгы белән расланган 2023 елда янгыннар чыгу куркынычы булган чорда Татарстан Республикасы территориясендә урман янгыннарын сүндерүнең җыелма планы нигезендә урман янгыннары белән көрәшү өчен җәлеп итеелә алган хезмәткәрләренә;

ведомствоара оператив, патруль, патруль-маневр, маневр, патруль-контроль мобиль төркемнәре эшендә катнашучы затларга;

үз компетенциясе чикләрендә урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген), урманнарны саклауны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларга;

урман янгыннарын профилактикалау чараларын үткәрүгә җәлеп ителгән яки җинаятьләрне һәм административ хокук бозуларны ачыклау һәм кисәтү буенча оператив тикшерү төркемнәре, патруль-контроль төркемнәре составына керүче полиция хезмәткәрләренә;

урманнарны саклау чараларын, шул исәптән урманнарны саклау, яклау, торгызу, урман үрчетү эшләрен, шулай ук Россия Федерациясе Урман кодексының 19 статьясы нигезендә урман хуҗалыгының алып барылышы чараларын гамәлгә ашыручы затларга;

диләнкеләр бүлү һәм аларга таксация ясау эшләрен, урман хуҗалыгы корылышы (җир корылышы) эшләрен, урманнарга дәүләт инвентаризациясен ясау эшләрен, урман патологиясе буенча дәүләт мониторингы эшләрен, селекцияләнгән орлыкчылык эшләрен башкаручы затларга;

линия объектларына (электр тапшыру линияләренә, элемтә линияләренә, юлларга, торба үткәргечләргә һәм әлеге объектларның аерылгысыз технологик өлеше булып торган корылмаларга) хезмәт күрсәтүче оешмаларның һәм учреждениеләрнең вазыйфаи затларына (ремонт бригадаларына);

урман утыртмаларын арендалау, түләүсез файдалану, даими (чикләнмәгән вакытта) файдалану шартнамәләре һәм сатып алу-сату шартнамәләре нигезендә урманнардан файдаланучы затларга;

гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан урман массивлары аша узучы гражданнарга һәм юридик затларга.

3. Гражданнарның урманнарда булуын һәм аларга транспорт чаралары белән керүен чикләүне кертү чорына гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү максаты белән Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Урман янгыннарын сүндерү үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең тәбәк диспетчерлык хезмәтенә элемтәгә керү өчен түбәндәге телефон номерларын билгеләргә: 8(843) 221-37-95, 8-800-100-94-00.

4. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына:

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы ведомство буйсынуындагы Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре

тарафыннан янгынга каршы профилактика чараларын үтәүгә дәүләт йөкләмәсе нигезендә урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү эшен оештырырга;

Татарстан Республикасы Рәисенең «2023 елда янгыннар чыгу куркынычы булган чорда Татарстан Республикасы территориясендә урман янгыннарын сүндерүнең җыелма планын раслау турында» 2023 елның 7 мартындагы 105 номерлы боерыгы белән расланган 2023 елда янгыннар чыгу куркынычы булган чорда Татарстан Республикасы территориясендә урман янгыннарын сүндерүнең җыелма планы нигезендә урман янгыннарын сүндерүгә бәйле һәлакәттән коткару эшләрен үткәрүне гамәлгә ашырырга;

тиешле чикләүне кертү турында һәм аның гамәлдә булу чоры турында кисәтү аншлагларын урнаштыруны оештырырга;

урман юлларына шлагбаумнар куюны оештырырга;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләрдә тәүлек буе кизү торуны оештырырга һәм урман массивларында патруль торуны көчәйтергә;

ял һәм бәйрәм көннәрендә урманнарда кешеләр күпләп ял итү урыннарында вакытлыча постлар оештырырга;

халыкка төбәк телеканалларында, радиотапшыру станцияләрендә, вакытлы басма матбугатларда табигать янгыннары торышы һәм урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылык турында өстәмә мәгълүмат бирүне оештырырга.

5. Республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләренә түбәндәгене гамәлгә ашырырга, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына, «Түбән Кама» милли паркы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең, «Идел-Кама дәүләт табигать биосфера тыюлыгы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең махсус саклана торган табигать территорияләре һәм Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Мари урманчылыгы – Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Урман хуҗалыгы һәм табигатьтән файдалану идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесе филиалы (Татарстан Республикасы территориясендә Суслонгер участок урманчылыгы) җитәкчеләренә, оешмаларга, иҗтимагый берләшмәләргә, индивидуаль эшмәкәрләргә, вазыйфаи затларга – гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә: Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 25 март, б-748 нче боерыгы нигезендә янгынга каршы кисәтү, профилактика чаралары комплексын үткәрүне тәэмин итүне.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның урманнарда булуын һәм аларга транспорт чаралары белән керүен чикләүне кертү турында» 2023 ел, 16 июнь, 722 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин